МБОУ «Верхнешипкинская ООШ» ЗМР

# ***Билингвальное образование как основа формирования общей культуры дошкольников***

*Воспитатель Хусниева Раушания Миннивакифовна*



# Из опыта работы:

***Обучение детей татарской национальности русскому языку через игру.***

“Для изучения языка гораздо важнее свободная любознателность, чем грозная необходимость”

Аврелий Авгучтин ”



***Обучение*** *детей русскому языку в детском саду - одна из самых сложных методических задач. Но сейчас стало интереснее, то есть дети теперь учатся играя. Игра - естественная форма детского существования. И самый прямой путь к достижению взаимопонимания с ребенком лежит через игровое действие.*





Своей методической темой я выбрала
“Обучение татароязычных детей русскому языку через игру”.

***Цель:*** *развитие языковой способности детей, ознакомление с русским языком, как средством общения посредством игр.*

*Главное в моей работе – вызвать желание общаться*

*сском языке. И в этом мне*












*Основной формой обучения русскому языку является занятие. Чтобы занятия получились интересными, я использую разнообразные пальчиковые игры, физминутки, песни, мультфильмы, презентации, сказки, подвижные, дидактические игры.*









# Занятия



*На каждом занятии мною проводятся фонетеческие упражнения, чистоговорки. Важно, чтобы каждый ребенок был во всех играх.*



*В ходе игр ребенок учится управлять движениями своих губ, языка, рта при произношении русских звуков и слов, пользоваться ударением и интонацией для точной передачи смысла слова и предложения.*

*Научиться говорить на русском языке означает не только выучить слова и фразы,но и воспитывать в себе толерантное отношение к культуре русского народа. Необходимо создавать культурную языковую среду, которая будет спсобствовать приобщению детей к русской культуре. С этой целью мы проводим праздники и развлечнеия, готовим инсценировки сказок на русском языке, организовываем просмотр мультфильмов.*



*Бүгенге көндә мәктәпкәчә яштәге балаларны ике телгә дә өйрәтүнең яңа системасы эшләнде.*

*Максаты - телләргә өйрәтү процессында яңа технологияләрне куллануны максат итеп куйды. Төрле телләргә өйрәтүдә заманча технологияләрне куллану ул - әхлаклы кеше тәрбияләү.*






*Хәзерге көндә милли балалар бакчалары очен - татар балаларына рус теленэ өйрәтү өчен төрле программалар һәм дәреслекләр төзеп бастырылды; методик кулланмалар һәм дидактик әсбаплар төзелде.*

*Региональ программыга таянып үз эшемдә төрле формалар кулланам. Программа бурычларын үтәүдә эш формаларының, практик гамәли алымнарның, чараларның әһәмияте зур.*



 

*Төп эш төрләре булып түбәндәгеләр тора:*

*1. Предметлар белән эш: тасвирлау, уенчык белән диалог төзү, уен һәм әкиятләрдә катнашу.*

*2. Рәсемнәр белән эш: тасвирлау, үстерешле диалог.*

*3. Сюжетлы-рольле уеннар;*

*4. Әйлән-бәйлән, җырлы-биюле уеннар өйрәнү (аудиоязмага таянып).*

*5. Театральләштерү, сәхнәләштерү (бармак театры, битлекләр, костюмнар, театр күрсәтү (әти-әниләргә, башка төркем балаларына).*

6. Хәрәкәтле уеннар.

7. Иҗади һәм ситуатив уеннар: рольле уеннар, интервью, ситуатив күнегүләр.

8. Ситуатив, логик күнегүләрне ишетеп, аңлап эшләү.

9. Үстерелешле диалоглар (зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара аралашу).

10. Аудиоязмалар тыңлау, карау, кушылып әйтү, җырлау, кабатлау, ишеткән сүзне рәсемдә табып күрсәтү.

11. Анимацион сюжетлар, мультфильмнар карау.

12. Интерактив уеннар.



Үз эшемне традицион булмаган методлар ярдәмендә алып барырга тырышам: театральләштерү, төрле театр геройларын кулланып үткәрәм. Шулай иткәндә балада кызыксыну уяна, шөгелне бирелеп тыңлый башлый, теләп катнаша.

*Рус теленә өйрәтүгә килгәндә, “Изучаем русский язык» С. Гаффарованың программасына нигезләнеп эш итәм. Күпчелек уеннар, хәрәкәтләр, этюд белән эшләү, психогимнастика, аудио-видеоязмаларны да кулланам. Татар телендәге текстларны рус теленә тәрҗемә итү, матур әдәбият белән таныштыру – боларның барысы да яңа методик алымнар буларак кулланыла.*



*Балаларга рус телен өйрәтү белән беррәттән, аларны рус халкының гореф-гадәтләре, матур йолалары, милли бәйрәмнәре, мәдәнияте белән таныштыру бурычы куйдым. Иң элек аларны тормышта еш кулланыла торган сүзләр белән таныштырам. “Здравствуйте”, “До свидания”, “Спасибо”, “Доброе утро” һәм башка сүзләрне гел кабатлап торабыз.  Истә калдыру өчен төрле уеннар оештырам, махсус күнегүләргә, методик алымнарга мөрәҗәгать итәм. Тагын шунысын да әйтәсе килә, дәрес барышында тәрбиячененң бары тик рус телендә генә сөйләшүе уңай күренеш. Ләкин телне яңа гына өйрәнә башлаган очракта балаларга биреләсе сораулар иң элек татарча, аннан соң рус теленә тәрҗемә ителеп бирелә.*



*Уеннар вакытында уенчыклар һәм реаль предметлар кулланыла. Уен вакытында бала предметларны чагыштырырга, охшаш һәм аерым якларын ачыкларга өйрәнә; предметларның үзенчәлекләре: төсе, зурлыгы, формасы, сыйфаты белән таныша. Соңыннан уенның эчтәлеге катлауландыра.*



*Баланы әйләнә-тирәдәге предметлар белән таныштырганда аның сөйләмен үстерүгә дә әһәмият бирергә кирәк. Предметлар, аларның исемнәре белән таныштыргач, сүзле уеннарда шул исем- атамаларны төрле вариантта куллану отышлы. Андый уеннар бала аңында сүзнең мәгънәви эчтәлеген киңәйтә, төрле сүзтезмәләр төзи белергә өйрәтә.*



*Мәсәлән, “Что это такое?” дигән уенны алыйк. “Какого цвета” дигән сораучга бала: агач, төрле җиләк җимешләрнең төсләре , уенчыкларның төсләрен  дөрес итеп  җавап бирә. Шунда ук чагыштыру ясарга да мөмкин. “Это фрукт или овощ?”- диярга була. Мондый вакытта бала чагыштыра, гомумиләштерә белергә өйрәнә, сүзенең абстракт мәгънәсен аңлый башлый.*

*Предмет белән уеннар аерым дидактик бурычларны да хәл итәргә ярдәм итә.*



*Өстәл уеннары - боларга парлы картиналар, лото, домино уеннары кирә.*

*Парлары буенча картиналарны сайлау максатыннан- балаларга башта иң гади биремнәр бирелә, мәсәлән, “Найди одинаковые шапки” , “Найди похожую пару”. Соңыннан бирем катлаулана бара: бала предметларны тышкы күренешләре белән генә түгел, мәгънәсе буенча да аера. Мәсәлән, барлык предметлы рәсемнәр арасыннан “Найди 2 одинаковых самолёта” , яисә “Найди 2 одинаковых яблока” (Бу очракта самолетлар яки алмалар төрле формада, төрле төстә ясалган була).*



*Картиналарны гомуми билгеләренә карап сайлап алу яки предметларны классификацияләү максатыннан,“ Что растёт в саду и в огороде?”, “Что сначала, что потом” уеннарын уйнатырга була.*

*Сүзле уеннар тәрбия чарасы буларак отышлы, чөнки алар барышында күмәклек, дуслык, игътибарлылык, ярдәмләшү кебек матур сыйфатлар, шулай ук бала күңелендә рус теленә карата кызыксыну уятабыз.Сүзле уеннарның шигырь калыбына салынган булуы балаларда эстетик зәвык тәрбияли, бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерергә ярдәм итә.*



*Уен өчен уңайлы шартлар тудыру да игътибар үзәгендә булырга тиеш. Кирәк-яраклар, кулланмалар алдан ук әзерләп куела. Кулланыла торган уенчыклар, җиһазлар балаларның игътибарын җәлеп итә торган ачык төстә, матур булсын. Аларны әзерләү, аннары тәртипләп урнаштыру эшләренә балаларны катнаштырырга кирәк. Алар бу вакытта пөхтәлеккә, чисталыкка өйрәнә, әйберләрне саклап тотарга күнегә.*



*Алда язылганнардан нәтиҗә ясап, шуны әйтергә телим: татар балаларын рус теленә өйрәткәндә яңалыклар агымында югалып калмыйча, тәрбиячегә дөрес юнәлеш алуны төп бурыч итеп куярга кирәк.*

*Татарча да яхшы бел,*
*Русча да яхшы бел,*
*Икесе дә безнең өчен*
*Иң кирәкле изге тел.*

*(Г. Тукай)*

